**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**СӘМӘКӘЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

# КАРАР

16 июль 2025 ел № 60/1

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Сәмәкәй авыл җирлеге Советының 2007 елның 05 июнендәге 67 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Сәмәкәй авыл җирлегендә халык тыңлауларын оештыру һәм үткәрү тәртибе турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

2020 елның 29 декабрендәге 468-ФЗ номерлы Федераль закон, Тукай муниципаль районы Сәмәкәй авыл җирлеге уставы нигезендә Сәмәкәй авыл җирлеге Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Сәмәкәй авыл җирлеге Советының 2007 елның 05 июнендәге 67 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Сәмәкәй авыл җирлегендә халык тыңлауларын оештыру һәм үткәрү тәртибе турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 14.2 пунктта «комиссия» сүзеннән соң «мондый фикер алышулар яки тыңлаулар тәмамланган көннән алып унбиш эш көне эчендә» сүзләрен өстәргә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru), рәсми сайтта (tukay.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә.

4. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны Сәмәкәй авыл җирлеге Советының законлылык һәм хокук тәртибе буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Сәмәкәй авыл җирлеге Советы Башлыгы,
Совет Рәисе И.М.Усманов